# «Җиләк җыю», «Җиләккә төшү» йоласы

Авыл халкы җиләк өлгерүне түземсезлек белән көткән, бигрәк тә балалар, җиләк өлгерүгә тау битләреннән, урманнан хуш исле каен җиләге, җир җиләге җыйганнар. Ә җиләкне җыю өчен кәрзин бик уңай булган, авыл халкы талдан кәрзин дә үргән бит әле ул.

Элек бит аның шикәре дә мулдан булмаган, шунлыктан җиләктән как ясаганнар, җиләкне киптергәннәр.













